ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ
КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ
ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

__13.03.2026____　　　　Казан шә һ ә ре　　　　№ _под-28/26_

Татарстан Республикасы «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең финанс тотрыклылыгын тәэмин итү, аның матди-техник базасын үстерү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын арттыру һәм ул төзелгән максатларга ирешү максатларында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүнең кушымтада бирелә торган Тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Татарстан Республикасы «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры әлеге боерык белән расланган Тәртипнең үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.
3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　В. Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең «13» __03__
2026 ел. № _под-28/26___
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү Тәртибе**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасының «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүнең әлеге Тәртибе (алга таба - Тәртип) түбәндәгеләргә туры китереп эшләнде:

- Рәсәй Федерациясе Бюджет кодексы белән;
- Рәсәй Федерациясе Салым кодексы белән;
- Рәсәй Федерациясе Гражданлык кодексы белән;
- Рәсәй Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән;
- «Биналар һәм корылмалар иминлеге турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон белән;
- «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон белән;
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәткән өчен (эшләр башкарган өчен) гражданнар һәм юридик затлар өчен түләүне билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 елның 30 декабрендәге 1170 номерлы карары белән;
- Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы «Төзелешендә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставын раслау турында» 2024 елның 7 августындагы 109 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе уставы белән;
- башка норматив хокукый актлар белән.

1.2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

Учреждение - Татарстан Республикасының «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба - Учреждение), аны гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башкара.

Кулланучы - түләүле хезмәт алучы физик яки юридик зат.

Түләүле хезмәтләр физик яисә юридик затларның биналарның һәм корылмаларның, аларның төзелеш конструкцияләренең техник торышын тикшерү, төзелеш, юл материалларына физик-механик сынаулар үткәрү, хезмәт күрсәтүләрне үстерүне һәм камилләштерүне тәэмин итү, учреждениенең матди-техник базасын ныгыту өчен өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өлкәсендәге ихтыяҗларын һәрьяклап канәгатьләндерү максатында күрсәтелә.

1.3. Түләүле хезмәтләр күрсәтү учреждениенең финанс-хуҗалык эшчәнлегенең бер өлеше булып тора.

1.4. Әлеге Тәртип түбәндәгеләрне билгели:

- түләүле хезмәтләр күрсәтү тәртибе;
- түләүле хезмәтләргә бәяләрне билгеләү тәртибе;
- түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән керемнәрне планлаштыру һәм алардан файдалану тәртибе;
- түләүле хезмәтләрне исәпкә алуны оештыру һәм түләүле хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген контрольдә тоту.

## 2. Түләүле хезмәтләр төрләре

2.1. Учреждение тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрнең төрләре Учреждение Уставында карала.

2.2. Учреждение Уставта каралмаган хезмәтләр күрсәтергә хокуклы түгел.

## 3. Хезмәтләр күрсәтүне оештыру

3.1. Түләүле хезмәтләр Учреждение тарафыннан шартнамә һәм хезмәт өчен түләү суммасын күрсәтеп, хезмәт өчен түләүнераслый торган документ нигезендә күрсәтелә.

3.2. Шартнамәнең яисә тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән башка документның формасы законнар нигезендә билгеләнә.

3.3. Түләүле хезмәтләр күрсәтелгәндә Учреждениенең билгеләнгән эш режимы саклана, бу вакытта дәүләт йөкләмәсе кысаларында күрсәтелә торган хезмәтләр кыскармаска һәм аларның сыйфаты начарланмаска тиеш, шулай ук түләүле хезмәтләр урынына яисә төп устав эшчәнлегенә зыян китереп күрсәтелергә тиеш түгел.

3.4. Хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары хезмәт күрсәтүгә шартнамә белән билгеләнә.

3.5. Учреждение кулланучыларны түләүле хезмәтләр күрсәтү турында түбәндәге күрсәтмә мәгълүмат белән тәэмин итәргә тиеш:

- Учреждениенең эш режимы;
- түләүле хезмәтләрнең бәясе күрсәтелгән төрләре;
- түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм алу шартлары;

3.6. Күрсәтелгән түләүле хезмәтләр өчен исәп-хисаплар билгеләнгән тәртиптә Учреждениенең шәхси счетына акча күчерү юлы белән акчасыз исәп-хисап ясала.

3.7. Учреждение түләүле хезмәтләрне мөстәкыйль рәвештә һәм (яисә) өченче затларны җәлеп итеп (бергә катнашып) Рәсәй Федерациясе законнары нигезендә төзелгән шартнамә нигезендә күрсәтә ала.

## 4. Түләүле хезмәтләргә бәяләрне билгеләү тәртибе

4.1. Түләүле хезмәтләр бәясен исәпләү «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) өчен түләүне билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.12.2010 № 1170 карары һәм (яисә) федераль смета нормативлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.2. Учреждение түләүле хезмәт күрсәтүләргә бәяләрне гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп раслый.

## 5. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрне планлаштыру һәм алардан файдалану Тәртибе

5.1. Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәрне планлаштыру түләүле хезмәтнең һәр конкрет төре буенча учреждение эшчәнлегенең сан күрсәткечләре нигезендә, тәртиптә, шулай ук Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Учреждение ел саен норматив хокукый актларда билгеләнгән срокларда бюджет классификациясе кодлары кисемтәсендә чираттагы финанс елына түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр килү фаразын төзи һәм Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә тапшыра.

5.3. Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән алынган һәм хезмәт өчен түләүгә, хезмәт өчен түләү буенча исәпләүләрне дә кертеп, һәм Учреждение хезмәткәрләрен кызыксындыру характерындагы түләүләргә җибәрелә торган керемнәр күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 21.09.2017 № 705 карары белән билгеләнә.

## 6. Түләүле хезмәтләрне исәпкә алуны оештыру һәм түләүле хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген тикшереп тору

6.1. Учреждение түләүле хезмәтләрнең бухгалтерлык, салым һәм статистик исәбен законнар нигезендә алып бара.

6.2. Түләүле хезмәтләр күрсәтү учреждениесе эшчәнлеген тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе, Татарстан

Республикасы Финанс министрлыгы һәм Учреждение эшчәнлеген законнар нигезендә тикшереп тору һәм күзәтчелек функцияләрен башкаручы башка органнар гамәлгә ашыра.

6.3. Түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм түләүле хезмәтләрдән керемнәрне исәпкә алу буенча Учреждение эшчәнлеген оештыру өчен Учреждение директоры җаваплы.